


ГАЗЕТА СЕВЕРО-ЗАПАДА ОРЕНБУРГСКОЙ ОБЛАСТИ № 8 (11) АВГУСТ 2009

## НОВОСТИ ТАТАРСКОГО МИРА

### Бәйләнешләр ныгый!

Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетында Искешәһәрдән (Төркия) килгән милләттәшебез, Казан татарлары мәдәни җәмгыяте рәисе Абдулвахит Ирдән белән очрашу булып узды.

Тарих битләренә күз салсак, Идел буе татарлары Төркиягә Х Х-ХХ гасырларда күчеп китәргә мәҗбүр булганнар. Бүгенгесе көндә аларның варислары Төркиянең төрле шәһәрләрендә, шулай ук күмәк рәвештә дүрт авылда гомер итәләр. Бу илгә беренчеләрдән булып тамырлары Татарстанның Лениногорск, Бөгелмә районнарына тоташкан милләттәшләребез күченә. Бүгенгәчә аларның нәселләре Искешәһәрдән ерак булмаган Османия авылында яшиләр. Безнең милләттәшләребез үз телләрен, гореф-гадәтләрен саклап кала алганнар, алар тарихи ватаннары белән элемтәләрне ныгытырга тырышалар. Ирдән әфәнде сүзләренә караганда, соңгы елларда чит илләрдәге татар яшьләренең туган тел, татар мәдәнияте һәм гореф-гадәтләренә игътибары арта бара. Җәмгыятьнең активистлары һәр ел Казан шәһәреннән артистлар чакырып Сабантуйлар, төрле кичәләр уздыралар. Казанның 1000-еллык юбилее алдыннан аларның тырышлыгы белән Татарстанның башкаласы һәм Искешәһәр арасында тугандаш элемтәләр урнаштырылды. Шулай да әлеге очрашуда Төркия кунаклары соңгы елларда бәйләнешләрнең йомшара баруын билгеләп үттеләр һәм шуңа бәйле мөнәсәбәтләрнең ныгытылырга тиешлегенә басым ясадылар.

Очрашу барышында Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе урынбасары Дамир Гыйсметдинов һәм бүлек җитәкчесе Марс Тукаев төрле авырлыкларга карамастан, БТК БК белән Төркиядәге милләттәшләребез арасында бәйләнешләр ныгыячак һәм тәрәккыйят ителәчәк дип белдерделәр. Бу мәсьәләдә халык дипломатиясе, ягъни гади кешеләр арасында элемтәләр урнаштыру зарури һәм бик мөһим, чөнки нәтиҗәдә алар дустанә һәм эшлекле мөнәсәбәтләргә әверелә.

### Сабантуй в Баку

9 августа в Азербайджане в пригороде столицы на территории ипподрома прошел национальный праздник Сабантуй. Открытие Сабантуя ознаменовалось, как и положено по народным традициям, выносом шеста — символа праздника. Юноши и девушки в ярких национальных костюмах танцевали под задорные тюркско-татарские мелодии. С приветствием к собравшимся на татарском, азербайджанском, английском, русском, французском языках обратились ведущие праздника. Прозвучало поздравление и приветствие Президента Республики Татарстан М.Ш. Шаймиева. Его зачитали заместитель министра культуры Татарстана Ирада Аюпова и председатель центра татарской культуры Азербайджана «Туган тел» Гюльджан Мясоутова. Поздравление от Председателя Исполкома Всемирного конгресса татар Рината Закирова озвучил Председатель Центра татарской молодежи Азербайджана Дияз Ахмеджанов. С праздником азербайджанских татар поздравил Чрезвычайный и Полномочный посол Российской Федерации в Азербайджане Владимир Дорохин. В своей речи он подчеркнул, что несмотря на татарские корни, Сабантуй в Азербайджане в своей сути транснационален, поскольку отмечают его как татары, так и азербайджанцы, русские, а также представители различных национальных меньшинств. «Татарская диаспора в Азербайджане является одной из активных среди общин дальнего и ближнего зарубежья» — отметила в своем выступление И. Аюпова. По ее словам, министерство в рамках новой концепции культуры планирует развивать в новом формате работу по укреплению культурных, гуманитарных связей с татарской диаспорой в мире, расширять диапазон такого сотрудничества. Также замминистра подчеркнула тот факт, что в культурном пространстве Азербайджана и Татарстана сочетаются традиции как Запада, так и мусульманского Востока.

tatar-congress.org

РЕПОРТАЖ

## КАЖДУЮ МИНУТУ — УБОРКЕ УРОЖАЯ



Утро 23 августа выдалось пасмурным, а ночью вообще шел дождь. Признаться, не ожидал, что в акционерном обществе «Алга» Асекеевского района уже с раннего утра кипит трудовая жизнь. Обычно в такой период дождей в колхозах отдыхали по домам.

Здесь же, чувствуется, работает отлаженный механизм трудового созидания.

Вот готовятся к въезду в поле комбайнеры Халиль Хуснуллин и Рамис Бакиров. Они вчера убирали поле вблизи поселка Курбанай. Сегодня с утра валки будут влажными, но тем не менее считают, что лучше ожидать погоды у кромки поле, чем дома. Вдруг прояснится. Тогда можно будет сразу приступить к уборке.

Их мощные «Клаасы» способны на многое. Спрашиваю у комбайнеров, где они учились управлять такой техникой. Оказывается, оба они начинали с малого, с обычных комбайнов и тракторов «Беларусь», потом освоили более сложную технику.

— С нынешними комбайнами никаких проблем, — замечает Халиль Ядкарович, — они по сравнению с теми комбайнами, как игрушки. Легко управляются, а, главное, надежны, что немаловажно, когда каждая минута дорога.

Судя по всему, механизаторы не теряют времени. Намолотили по 24 тысячи центнеров зерна, что по нынешнему году совсем неплохо.

Уборочная страда, другие сельскохозяйственные работы идут своим чередом. Отличных результатов, к примеру, добиваются трактористы Фаиль Насертдинов, Ильдар Усманов, Алексей Симонян. Он тоже в числе лидеров.

Солнце ближе к зениту. Слышен рокот тракторов, снуют машины — все движется, все работает, а это главное.

**М.ГАЯЗЕТДИНОВ.**

**На фото:** комбайнеры Халиль Хуснуллин и Рамис Бакиров, «Клаасы» готовы к битве за урожай.



## Слово редактора

Издание газеты — дело не легкое, особенно когда начинаешь с нуля. Не было у нас ни базы, ни особых возможностей, а был лишь энтузиазм и огромное желание создать газету, которая рассказывала бы о жизни татар и не только северо-западных районов области.

Одолены многие бюрократические препоны, газеты вышла на подписку. Теперь достаточно обратиться в почтовые отделение или просто к почтальонам, чтобы оформить подписку и получать газету дома.

Конечно, мы рассчитывали, что подписная компания, проведенная в июне, даст больше результатов. Ведь была проделана огромная работа. Мы побывали почти в каждой татарской деревне всех шести районов распространения газеты. Выпускали рекламные листки. Постарались, чтобы сигнальные номера попали в каждый дом. Это стоило и средств, и труда, и времени.

Надо отметить, что весомую помощь в рекламе газеты оказали наши коллеги из «Абдулинских просторов», из Матвеевской «Новой жизни», Пономаревских «Демских зорь», «Бугурусланской правды». Редактор газеты «Малая Родина» Петр Членов давал советы и консультации по тем или иным рабочим вопросам. Руководители этих газет не считают нас конкурентами, потому что мы несколько другого формата и нашли свою нишу в информационном поле региона.

А вот помощи от тех, на кого мы безусловно рассчитывали, так и не получили. Можно сказать, игнорировали газету руководители хозяйств и главы администраций многих татарских сел и деревень. Конечно, они не обязаны нам помогать. Но могли бы как-то поучаствовать в жизни первой асекеевской татарской газеты.

Коллеги называют несколько причин скромных результатов нашей подписки. Оказывается, летом сельчане, занятые работой на подворьях и приусадебных участках, традиционно подписываются мало. Вторая причина — мы с некоторым запозданием начали подписную кампанию на полугодие.

Но наступает осень, и мы все-таки ожидаем, что тираж заметно увеличится. А чем выше тираж, тем интереснее и разнообразнее будет газета.

**Фарит НУГУМАНОВ.**

СУБЪЕКТИВНО ОБ ОБЪЕКТИВНОМ

# РОДНОЙ ЧУЖОЙ ГОРОД



Казань многие считают не только столицей Татарстана, но и своего рода главным городом всех татар проживающих на земле. Поэтому всегда с неким душевным трепетом посещаешь этот город и чувствуешь себя здесь совсем, как дома. Некоторые мусульмане, приезжающие в Казань в гости, не читают здесь молитву путешественника «сафар», так как считают, что возвратились домой, на землю предков. Вспоминается 2002 год. Дни заседания Всемирного Конгресса татар. Нас, гостей конгресса, тогда чуть ли не на руках носили. Слышны были только татарские речи. А концерты, а встречи? Сколько незабываемых часов и дней! Многие делегаты, до этого почти не знавшие родного языка, именно здесь почувствовали себя татарами. Они слушали своих соплеменников и стыдились брать в руки наушники, в которых велся синхронный перевод выступлений на русский. И что поразительно, начинали понимать как бы на генетическом уровне родную речь.

Когда едешь в Казань, односельчане, знакомые просят привезти ту или иную книгу, мусульманский календарь, диски с записями музыки и песен и многое другое. Их представление о столице сформировано передачами ТНВ. Будто целыми днями в Казани поют и пляшут и разговаривают только на татарском языке.

Да, здесь есть "очаги", в которых не только тлеет, а горит национальная жизнь. Культура, образование, театры. Кипит татарская жизнь в том же Конгрессе. Но все это производит впечатление каких-то внутренних тусовок по интересам, в которых принимают участие сравнительно небольшое количество одних и тех же людей. А сам город, особенно подальше от Площади Свободы, живет своей жизнью. Она один к одному сравнима с жизнью любого другого российского города, как то, к примеру, Самара или Оренбург.

В официальных учреждениях есть вывески на татарском языке. У входов в магазины таких дублирующих вывесок гораздо реже. Существенно увеличилось количество вывесок и рекламы на английском. Видимо, в рамках подготовки к Универсиаде-2013. Из двух десятков телевизионных каналов, разве что на двух можно услышать татарскую речь. Примерно такое же положение на радио. В газетных киосках я не сразу обнаружил не то что изданий на языке Тукая, вообще татарстанские издания.





Но это, может, не так важно. Сама атмосфера! Я ради эксперимента пытался разговаривать на рынке и просто на улице по-татарски. Вот идет явно татарин. Спрашиваю, как пройти на улицу Шамиля Усмана. Смотрит, как на идиота. В его глазах уже вижу диагноз: приехал, мол, деревенщина, по-русски говорить даже не умеет. Татарская речь? Ее не услышишь в большинстве офисов, приемных и даже магазинах. Разве что на транспорте можно случайно подслушаешь старушек, разговаривающих на татарском языке. Молодежь, кажется, вообще на родном не говорит. Это не модно, "безпонтово".

В первый раз готовясь к поездке в Казань, штудировал самоучитель татарского языка, дабы не ударить в грязь лицом. Теперь понял свою ошибку. Бывая в Казани, обычно посещал организации, занимающиеся татарской проблематикой, и татарские СМИ. Поэтому казалось, что везде атмосфера такая.

Наверное, все это веление времени: глобализация, урбанизация, стандартизация. Но я вновь убедился, что единственной хранительницей родного языка, традиций и культуры по-прежнему является татарская деревня. Уж здесь всласть наслушаешься татарские речи и песни. А уж о наследии вообще можно говорить часами.

Точно так же, как за религией не надо ехать в Мекку, за истинно татарским — не стоит отправляться в Казань. Конечно, это столица Татарстана и татар, но все же нечто родное, передаваемое в наследие от дедушек и бабушек живет не там, а в каждом из нас. Если, конечно, мы сами его не вытравим из себя.

**Ф.ГАЯЗОВ.**
**Казань.**

**На снимке:** красоты Казани.

**Фото автора.**

АВЫДАШЛАР

# Зиянгуловларның алтын көзләре

Һәр гаиләнең бәхетләре бертөрле диләр. Шулайдыр инде, тынычкына гап гади яшәү — бәхетдер ул. Менә, Иске Солтанголда яшәүче Юсуп абый белән Хәния апа Зиянгуловлар шулай акрын гына инде илле елдан артык торалар.

Мондый матур тормышның асылын безгә Юсуп абый ачты:

- Бергә тору кагыйдәләре бик гади: бер береңне тыңлап, юл куеп яшәү иң мөһиме! Үз горурлыгыңны бераз тыеп, иптәшеңнең сүзен тыңлап яшәргә кирәк. Шулай Хәния апаң белән 54 ел торабыз инде.

Юсуп абый үзе Иске Солтангол малае, балачагы авыр сугыш вакытына туры килде. Сугыш башлангач, 11 яшьтән Юсуп абый колхозда водовоз булып хезмәт иткән. Аннарысоң, мәктәп еллары үткәч, ФЗОга Магнитогорск шәһәренә китә. Анда 2 ел экскаватор йөртүчегә укый. Укудан соң, тагын ике ел эшләгәч, яшь малай әрмия сафларында 3 ел хезмәт итә, аның ике елы Германиядә үтә.

Хезмәт иткәннән соң, Юсуп абый туры туган йортына кайта. Анда аны әти-әниләре, апайлары көтә.

Шушы вакытларда Юсуп абый Хәния апаны очрата.

- Без озак сөйләшеп тормадык, — ди Юсуп абый, — бер генә сөйләштек.

Икенче яклардан килгән яучыларны кире борып, Хәния апа Юсуп абыйга тормышка чыга. Шулай, 1955 елның салкын декабрь аенда дөньяга Зиянгуловлар гаиләсе килә.

Хәния апа — Яңа Солтангол авылы кызы. Мәктәпне бетергәннән соң кияүгә чыга, һәм гомер буе колхозда эшли.

Шулай бергә тормыш итә башлаганнан соң, озак үтми, беренче кызлары Хәлимә туа. Бераздаң, гаилә авылның яңа урамына йорт сала. Бу йортта тагын ике балалары — Таһир белән Мәдинә туа.

Юсуп Габдрахманович Нефтепроизводствога эшкә китә, бер ничә елдан, газ тутыру станциясенә эшкә урнаша. Шуннан пенсиягә чыга. Үзе күп орден — медальләргә лаек була. Алар арасында — хезмәт ветераны, ударник труда, "Труд и доблесть", "За Победу над Германией". Эшләгәндә дә грамотасыз, премиясез бер елы да үтмәде.

Көннәр ага, айлар — еллар ага, балалар төрле якларга тарала, ләкин, өчесе дә укытучы һөнәрен сайлый.

Олы кызлары Новосергиевск районында ире белән ике бала үстерә. Юдинка авылында, урта малайлары Таһир мәктәп директоры булып эшли, гаиләсендә бер малай да бер кыз. Шулук авылда, кече кызлары тормыш иптәше белән ике малай үстерә. Күптән түгел, Юсуп абый белән Хәния апа карт бабай һәм карт әби булдылар — онықларында кечкенә кызлары туды.

Шундый тату гаиләләр, якты, ачык картлар яшь парларга үрнәк булса иде. Бергә торалмыйча, уртак тел табалмыйча, аерылышкан яшьләр, алтын көзгә җиткән картларга карап үз тормышларын корса иде.

**Алсу ХАФИЗ.**
**Тольятти — Иске Солтангол.**



# МЕСЯЦ РАМАДАН

**Обращение Председателя Совета муфтиев России муфтия шейха Равиля ГАЙНУТДИНА к мусульманам России накануне начала священного месяца Рамадан**

**Дорогие единоверцы братья и сестры, россияне!**

21 августа для мусульман начинается главный пост — пост месяца Рамадан, время усердного поклонения Всевышнему.

Рамадан — это месяц «в который был ниспослан Коран в руководство для людей и как разъяснение прямого пути » ( Св. Коран, 2:182).

Пост месяца Рамадан — один из важнейших столпов нашей благословенной религии, месяц осмысленного выбора прямого пути, который мы целиком посвящаем глубокому познанию Аллаха и Его Слов — Священного Корана, основ Ислама — религии, ниспосланной нашим Творцом.

В течение тридцати дней мусульмане от утреннего рассвета до захода солнца воздерживаются от еды и питья. Однако такое воздержание — лишь внешняя сторона соблюдения поста. Главное же в Рамадане то, что это время, которое мы целиком посвящаем глубокому познанию Всевышнего Аллаха и Его Слова.

Искреннее выполнение своих обязанностей перед Всевышним дает в полной мере прочувствовать дары, скрытые Им в поклонении. Пост напоминает нам о существовании бедных и нуждающихся и побуждает нас к милосердию. Милосердие и миролюбие — главные черты нашей благословенной религии. Живя в большом и глобальном мире, мы, российские мусульмане помним и соблюдаем столпы своей веры. Самое главное для нас, мусульман — это сохранить себя на пути истины и веры, на пути, указанном самим Всевышним.

Пост месяца Рамадан — это испытание крепости нашей веры, милосердия наших сердец, чистоты наших помыслов и благородства наших поступков. Пост — это испытание, пройдя через которое мы очищаем свою душу и укрепляем свой разум.

Пост — путь к совершенствованию нашего благочестия, путь к духовному очищению, возможность осознания необходимости совершения добродетельных поступков, добрых дел. Пост это время когда человек учится состраданию и сочувствию тем, кто нуждается в нашей поддержке и нашей помощи.

Ислам не ограничивает человека лишь исполнением религиозных обязанностей, наша религия призывает всех верующих быть активными членами общества, принимать многообразие мира. Ислам учит, что наличие на земле разных народов с их своеобразием языков, культур, традиций, установлено Всевышним, Аллахом:

«О люди! Воистину, создали Мы вас мужчинами и женщинами и сделали народами и племенами, чтобы вы познавали друг друга. Ведь самый благочестивый из вас перед Аллахом тот, кто наиболее богобоязненный » (Коран, 49:13).

Российские мусульмане всегда гордились тем, что являются частью большой семьи народов и важно, чтобы в этой семье всегда царили мир и согласие. История учит, что попытки диктата какой-то одной культуры, одной цивилизации, также как диктат со стороны одного государства, однополярность силы неизбежно порождали конфликты, разрушая мир и уничтожая жизни.

Только многополярный мир, многовекторность в культуре способны дать человечеству шанс продлить дарованный Всевышним земной путь. Важно не утратить межнациональный и межрелигиозный мир в России, сердцевиной которого является проверенное веками братство православных и мусульман, которые вместе всегда не только составляли подавляющее большинство населения России, но вместе с представителями других традиционных религий нашей страны творили ее историю. Единение усилий важно во все времена и, особенно, в период кризиса, когда возникшие препятствия в развитии общества и экономики могут и должны усилить духовное развитие. Сегодня человечеству дана еще одна возможность верно истолковать и разумно использовать то, что было ниспослано для людей размышляющих в божественном учении.

В целях лучшего познания друг друга важно сохранять и культивировать дух веротерпимости и взаимоуважения, направленные на изучение других культур и религий и избегать, искоренять стереотипы недопонимания и вражды.

Мусульмане России во все времена подтверждали приверженность межнациональной и межконфессиональной толерантности, которая на протяжении веков является основой взаимоотношений народов нашей России, представителей разных национальностей и вероисповеданий.

Исторически сложившаяся традиция добрососедского сосуществования последователей различных культур и религий и сегодня позволяет находить общие решения в диалоге конфессий, в диалоге народов.

Духовному очищению, осмыслению земного пути, возвышению мыслей и чувств, а главное, укреплению веры посвящен наш пост.

Ураза-Байрам — праздник завершения поста Священного месяца Рамадан, приходится в этом году на 20 сентября . Для нас это день общей радости, счастливого времени обретения искренности и душевной гармонии.

От имени Совета муфтиев России, Духовных управлений мусульман нашей страны и от себя лично еще раз сердечно поздравляю вас, моих братьев и сестер-единоверцев, соотечественников с наступлением светлого месяца Рамадан!

Я желаю всем вам снискать Его Благословение и Милость.

Молю Всевышнего даровать всем нам мир и радость, счастье и здоровье, успех и благополучие, милость и благоденствие!

**20 августа 2009**
**С сайта Совета Муфтиев России:**
**www.muslim.ru**

# РАМАЗАН АЕ

**ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең Рамазан ае башлану уңаеннан Татарстан мөселманнарына мөрәҗәгате.**

**Мөхтәрәм мөселман кардәшләр!**

Һәрберебез тормышында күптән көтеп алган вакыйга — Изге Рамазан ае башлану, ул — бөтендөнья мөселманнары тарафыннан шатлык һәм шул ук вакытта тетрәнеп каршы алынучы вакыйга да. Бу айда һәрберебез Аллаһы Тәгаләдән гөнаһларыбызны гафу итүне- ярлыкауны сорый, аның рәхим-шәфкатенә өметләнә һәм мөселманнар үзләре дә изгелекләр эшләргә омтыла.

Изге айның мөһим өркәнебаганасы, ул — тәкъвалык. Нәкъ менә шуннан чыгып Аллаһы Тәгалә безнең кылган гамәлләребезне бәяли, ә инде Рамазан аенда аның әҗере, буләкләве 70 мәртәбәгә артыр. Шуңа да башкарган игелекләр һәм шул ук вакытта кылган гөнаһларның нәтиҗәләре хакында да онытырга ярамый. Исегездә тотыгыз, беребез дә хаталардан хали түгел, әмма ялгышучыларның иң хәерлесе— хаталарын таныган, аңлаган һәм тәүбәгә килгәне.

Татарстан — Россиянең аеруча бер мөһим төбәге. Республикада елдан-ел рухи-әхлакый яңарышның тагын да үсүен-үзгәрүен, үзенчәлекле бер йөз алуын күрәбез: мәчетләр салына, аларга йөрүче яшьләрнең саны арткannан-арта бара, мәдрәсәләр төзелә һәм анда безнең халык дин нигезләрен үзләштерә, белем эсти, эре шәһәрләрдә мөселман инфраструктурасы үсеш ала. Әгәр дә җәмһүриятебездә бердәмлек, тынычлык һәм бар халыклар да дустанә мөнәсәбәттә яшәмәсә, боларның берсен дә тормышка ашыру мөмкин булмас иде.

Безнең республика төрле конфессияләрнең үзара килешеп яшәве белән данлыклы һәм әлеге үрнәк төрле яклап үсеп килүче җәмгыятьне торгызуга йогынты ясамый калмый. Республикада тынычлык һәм иминлек булу — Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең озак еллар дәвамында һәръяклап үлчәнгән һәм акыллы сәясәтенең нәтиҗәсе.

Мөселман дин әһелләренең Россия Президенты Дмитрий Анатольевич Медведев белән очрашуы быел аеруча мөһим вакыйга булды һәм анда мөфтиләр дәүләт башлыгына өметышаныч белдереп, мөселман өммәтен борчыган кичектергесез хәл итәсе мәсьәләләрне дә җиткерә алдылар.

Тормыш сынауларсыз була алмый һәм шуңа ышанабыз ки, Аллаһы Тәгаләнең юллаган сынаулары безне тагын да акыллы һәм нык булырга өйрәтә. Рухи торгынлыктан башка бер кризис та куркыныч түгел. Әгәр дә җәмгыятьтә рухи әхлаксызлык, рәхимсезлек тамыр җәя һәм кеше бу җиргә ни өчен килгәнен аңламау дәрәҗәсенә төшә икән, бернинди дә матди байлык мөһим булмаячак.

Шуңа да Аллаһтан киләчәк изге Рамазан аенда безгә рәхим-шәфкать, аннан ярлыкауны, һәр йортка, һәр гаиләгә, һәркайсыбызга бәхет һәм муллык индерүен сорыйбыз. Раббыбыз безнең җәмгыятьне төрле бәлаказалардан, бәхетсезлек һәм ярлылыктан сакласын иде. Аллаһы тынычлык, иминлек һәм сынауларда түземлек насыйп әйләсен.

Хак Тәгалә сезнең изге ниятләрегез, эшләрегез һәм казанышларыгызны зурласын. Әмин.

**Госман хәзрәт ИСХАКЫЙ.**
**www.e-islam.ru сайтыннан.**





## Җырчылар

Җырчылар хәзер күбәйде,
Мин түгел, кеше сөйли;
Сүзләрен дә үзе яза,
Көен дә үзе көйли.

Кемнәр генә җырламыйлар,
Экраннан карыйбыз;
Кайберләре кырыгыр тапкыр,
Карый, карый арыйбыз.

Җырлары да матур түгел,
Так себе, алдап кына;
Аны тыңларга ярата
Хезмәттәге солдат кына.

Кая хәзер яшь Илһамнар,
Зөһрә кебекләр кайда?
Акча чире һәр кешедә,
Буш җырлаудан ни файда.

Миндә шулай җырлар идем
Әгәр акча бирсәләр.
Кая ди ул, үтерерләр
Акчаң барын белсәләр.

Заманасы хәзер шундый,
Кешене кеше ашый;
Берәү эшләп тә ала алмый;
Берәү җырлап акча ясый.

## Балык

Су буенда утырам.
Балык тотарга исәп;
Салам алам, алам салам
Бер дә эләкми нишләп?

Утырам байтак, сәгәть,
Бер чиртеп тә карамый;
Әллә урыны килешми,
Әллә үзем ярамыйм.

Утырам, обед җитте,
Инде түземлек бетте;
Кармагымны сындырдым да
Сүгенеп кайтып киттем.

Балык әләгә балыкчыга
Безгә түгел тотсак та;
Безгә дигәнен саталар
Кибеттә, аргы якта.

## Аракы

Аракыны хәмер диләр,
Хәмер шайтан сидеге;
Хәмер эчкән кешеләрнең
Юк бездә иге-чиге.

Бала туса да эчәбез,
Кышын бозау туса да;
Исереп алгач төннәрне
Үткәрәбез тупсада.

Аракыны харам диләр
Меселмән кешесенә;
Харам булса да эчәләр
Бер ярты өчесенә.

Аракы бит берәүләргә
Ярамый, диләр, зарар;
Талаштыра, килештерә
Юк түгел, файдасы бар.

**Сафиулла ӘҺЛИУЛЛИН.**
**Иске Мөәмин авылы.**





## ТАТАР ХАЛЫК АШЛАРЫ

### Салкын эчемлекләр

Әзерләү ысуллары һәм тәмнәре буенча эчемлекләр бик күп төрле була. Аларны яңа җыйган һәм кипкән җиләк-җимештән, бал, шикәр, арыш, арпадан, салат оны, арыш ипие, колмак яисә чүпрәдән әзерлиләр. Мондый эчемлекләрне өй шартларында әзерләү кыен түгел.

Ләкин шуны истә тотарга кирәк: яңа җыйган җиләк-җимеш эчемлекләрнен озак кайнатырга ярамый, югыйсә аларның витаминнары бик күп югала. Суыткан җиләк-җимеш эчемлекләренә теләгән кешегә лимон кислотасы да салырга мөмкин.

### Йөзем җимешеннән эчемлек

Чистарткан йөземне салкын су белән юып әзер шикәр сиробына салырга да ут өстенә куярга. Эчемлекне, кайнап чыгуга, уттан алып 6-12 сәгать салкын урында тоталар. Җимешләр төпкә утыргач, иләктән сөзеп яңадан суыткычка яки базга куярга.

**1 л суга: 150-200 г йөзем җимеше, 100 г шикәр.**

### Караҗимеш эчемлеге

Бозылганнарыннан аралган, юган караҗимешне салкын суга салалар да шикәр комы өстиләр һәм кайнатып чыгаралар. Салкынча урынга куялар, суынгач сөзәләр. Шикәр урынына бал салырга, лимон кислотасы өстәргә мөмкин. Табынга салкын килеш бирелә.

**1л суга: 200-250 г караҗимеш, 150 г шикәр яки 80 г бал.**

### Лимон эчемлеге

Лимонны салкын су белән юарга, түгәрәкләп кисеп кайнаган баллы суга салырга да болгатырга һәм кайнатып чыгарырга; суыткач сөзәргә, лимонны икенче савытка сыгып, сөзгән эчемлеккә кушарга, болгатырга һәм салкын көе табынга бирергә.

**1 литр суга: 3 лимон, 150 г шикәр.**

### Балдан ясаган эчемлек

Кайнар суга бал салып 3-4 минут кайнатыла. Теләгән кешегә лимон кислотасы да салырга мөмкин. Эчемлек үтә күренмәле булырга тиеш, шуңа күрә аны әйбәтләп сөзәргә кирәк. Табынга салкын килеш бирәләр.

**1 стакан эчемлек әзерләү өчен: 20-25 г бал, 1г лимон кислотасы.**

### Җиләк эчемлеге

Мондый эчемлекләр ике-өч төрле җиләктән ясала. Алар витаминнарга бик бай һәм файдалы. Башта шикәр белән бергә кипкән җиләк-җимеш салып кайнаталар, аннары, яңа җыйган җиләкләр өстәп тагын 10 минут кайнаткач, салкынга куялар. Сөзеп, табынга салкын килеш бирергә.

**1 литр суга 50 г караҗимеш, 50 г йөзем җимеше, 50 г балан, 150 г шикәр**

## НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

(время местное)



| сентябрь | Фаджр Иртә | Восход Кояш чыга | Зухр Өйлә | Аср Икенде | Магриб Ахшам | Иша Ясту |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 6-36 | 7-36 | 15-10 | 19-29 | 21-29 | 22-59 |
| 2 | 6-38 | 7-38 | 15-10 | 19-28 | 21-26 | 22-56 |
| 3 | 6-40 | 7-40 | 15-10 | 19-23 | 21-23 | 22-53 |
| 4 | 6-41 | 7-41 | 15-10 | 19-21 | 21-21 | 22-51 |
| 5 | 6-43 | 7-43 | 15-10 | 19-19 | 21-19 | 22-49 |
| 6 | 6-45 | 7-45 | 15-10 | 19-17 | 21-17 | 22-47 |
| 7 | 6-47 | 7-47 | 15-10 | 19-14 | 21-14 | 22-44 |
| 8 | 6-49 | 7-49 | 15-10 | 19-11 | 21-11 | 22-41 |
| 9 | 6-50 | 7-50 | 15-10 | 19-09 | 21-09 | 22-39 |
| 10 | 6-52 | 7-52 | 15-10 | 19-07 | 21-07 | 22-37 |
| 11 | 6-54 | 7-54 | 15-10 | 19-05 | 21-05 | 22-35 |
| 12 | 6-56 | 7-56 | 15-10 | 19-02 | 21-02 | 22-32 |
| 13 | 6-58 | 7-58 | 15-10 | 18-59 | 20-59 | 22-29 |
| 14 | 7-00 | 8-00 | 15-10 | 18-57 | 20-57 | 22-27 |
| 15 | 7-02 | 8-02 | 15-10 | 18-55 | 20-55 | 22-25 |
| 16 | 7-04 | 8-04 | 15-10 | 18-52 | 20-52 | 22-22 |
| 17 | 7-05 | 8-05 | 15-10 | 18-49 | 20-49 | 22-19 |
| 18 | 7-06 | 8-06 | 15-10 | 18-46 | 20-46 | 22-16 |
| 19 | 7-07 | 8-07 | 15-10 | 18-43 | 20-43 | 22-13 |
| 20 | 7-09 | 8-09 | 15-10 | 18-40 | 20-40 | 22-10 |
| 21 | 7-11 | 8-11 | 15-10 | 18-38 | 20-38 | 22-08 |
| 22 | 7-13 | 8-13 | 15-10 | 18-36 | 20-36 | 22-06 |
| 23 | 7-15 | 8-15 | 15-10 | 18-34 | 20-34 | 22-04 |
| 24 | 7-17 | 8-17 | 15-10 | 18-31 | 20-31 | 22-01 |
| 25 | 7-19 | 8-19 | 15-10 | 18-28 | 20-28 | 21-58 |
| 26 | 7-21 | 8-21 | 15-10 | 18-26 | 20-26 | 21-56 |
| 27 | 7-23 | 8-23 | 15-10 | 18-24 | 20-24 | 21-54 |
| 28 | 7-24 | 8-24 | 15-10 | 18-22 | 20-22 | 21-52 |
| 29 | 7-26 | 8-26 | 15-10 | 18-19 | 20-19 | 21-49 |
| 30 | 7-27 | 8-27 | 15-10 | 18-16 | 20-16 | 21-46 |

**Данные предоставлены Бугурусланским муфтиятом. Возможна разница во времени в сравнении с другими источниками, на 3-5 минут. (Время летнее).**

ТУГАН ЯК
РОДНОЙ КРАЙ

**УЧРЕДИТЕЛЬ:** ТАТАРСКАЯ НАЦИОНАЛЬНО КУЛЬТУРНАЯ АВТОНОМИЯ
**АДРЕС РЕДАКЦИИ:** С.АСЕКЕЕВО, УЛ.ЧАПАЕВА 24.
**ТЕЛЕФОН:** (353-51) 2-22-81

Распространяется в Асекеевском, Абдулинском, Бугурусланском, Матвеевском, Пономаревском, Северном районах. Свидетельство о регистрации ПИ №ТУ 56-00065, выданное Управлением Федеральной службы по надзору в сфере связи и массовых коммуникаций по Оренбургской области.

Газета отпечатана в Бугурусланской типографии. 461600, г. Бугуруслан, ул. Революционная, 14.

Цена свободная. ТИРАЖ: 1000 ЭКЗ.

**E-MAIL:** tugan-iak-asekeevo@yandex.ru

**Главный редактор: Фарит НУГУМАНОВ**